**ГЛАВА ВОЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВОЙКИНО АВЫЛ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**02.12.2021** с. Войкино **20**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлегенең Базяково авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлеге Уставы нигезендә

карар бирәм:

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.

2. Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлегенең Базяково авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 18 декабреннән 19 декабренә кадәр график нигезендә билгеләргә (Кушымта).

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Войкино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- кышкы һәм җәйге чорда торак пунктларның юлларын төзекләндерү;
- янгынга каршы гидрант сатып алу;
- Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл сатып алу;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту;
- торак пунктларда урамнарны яктырту;
- трактор тотуга чыгымнар.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Войкино авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ   ЮК».

4. Әлеге карарны Войкино авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Войкино авыл җирлеге башлыгы** **Н.П. Шәбетдинова**

Кушымта

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының
Войкино авыл җирлегенең Базяково авылында
үзара салым кертү мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын этаплап уздыру
ГРАФИГЫ

| Тәртип саны | Үткәрү датасы | Үткәрү вакыты | Үткәрү урыны | Урамнарның исеме |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 18.12.2021 | 10-00 | Базяково ав., Федин ур., 20 й. Базяково АМЙ бинасы | |
| 2 | 18.12.2021 | 14-00 | | |
| 3 | 19.12.2021 | 10-00 | | |
| 4 | 19.12.2021 | 14-00 | | |